РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
АДАВ-ТУЛУМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АДАВ-ТОЛЫМБАЙ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

07.09.2021ел № 2-25

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Адав-Толымбай авыл җирлеге муниципаль
берәмлеге территориясендә төзекләндерү
кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының 2019 елның 5 декабрендәге 20 номерлы «Муниципаль берәмлекләр территорияләрен карап тотуга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» һәм СанПиН 2.1.7.3550-19 нормаларын раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге 2-37 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары белән расланган (2018 елның 16 июлендәге 3-46 номерлы, 09.09.2019 № 1-67, 05.08.2020 № 1-88, 24.12.2020 № 1-9, 15.07.2021 № 2-23 карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә (алга таба - Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. I бүлек:

6 пунктның 27 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«рөхсәтсез чүплек – калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру, саклау һәм күмү, утильләштерү, зарарсызлау, күмү максатларында унбер айдан артык вакытка калдыклар урнаштыру объектларының дәүләт реестрына кертелмәгән объектларда калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру, саклау һәм күмү»;

1.2. III бүлек:

55.5., 55.6 пунктларын төшереп калдырырга;

55.5 -55.10 пунктларның нумерациясен 55.5 – 55.8 пунктларның нумерациясе дип санарга;

68 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«68. Инженерлык челтәрләрендә планлы эшләр башкарганда, канализация агынты суларын якындагы канализация челтәре, су һәм җылылык челтәрләреннән - яңгыр канализациясенә (булганда) агызыла. Юлга су агызу тыела.

Шәхескә яки гражданинның мөлкәтенә, шулай ук юридик зат мөлкәтенә китерелгән зыян, зыян китергән зат тарафыннан тулы күләмдә капланырга тиеш.

Зыянны кайтару бурычы зыян китерүче булмаган затка йөкләнергә мөмкин.

Закон яки килешүдә зыян китерүченең зыян күрүчеләргә зыянны каплаудан тыш компенсация түләү бурычы билгеләнергә мөмкин. Закон нигезендә зыян китермәүче затның зыян күрүчегә зыянны каплаудан тыш компенсация түләү бурычы билгеләнергә мөмкин.

Әйләнә-тирә мохиткә аның пычрануы, ярлылануы, бозылуы, юкка чыгару, табигать ресурсларын рациональ файдаланмау, табигый экологик системаларны, табигый комплексларны һәм табигать ландшафтларын деградацияләү һәм җимерү һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарны башкача бозу нәтиҗәсендә зыян китергән юридик һәм физик затлар аны кануннар нигезендә тулы күләмдә капларга тиеш.»;

99.1 пунктын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«99.1. Торак пунктларда яисә оешма территориясендә чит кешеләр керә алмаслык итеп җитештерү территорияләре һәм эшләр участоклары чикләнгән булырга тиеш.

Саклаучы киртәләр конструкциясе түбәндәге таләпләрне канәгатьләндерергә тиеш:

җитештерү территорияләрен киртәләүнең биеклеге кимендә 1,6 м, ә эшләр участоклары кимендә 1,2 м булырга тиеш;

кешеләр күпләп уза торган урыннарга якын урнашкан коймалар 2 метрдан да ким булмаган биеклеккә ия булырга һәм тоташ саклагыч өскорма (козырек) белән җиһазландырылырга тиеш;

өскорма (козырек) кар авырлыгын тотарга, шулай ук аерым вак предметлар төшүдән сакларга тиеш;

эш вакыты дәвамында тикшерүдәге һәм эштән соң бикләнүче капка, ян капкалардан тыш коймаларда башка керү-чыгу урыны булмаска тиеш.»;

102.1. пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«102.1. торак зонасы янында, шәхси һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүгә бәйле булган коткару, авария-торгызу һәм башка кичектергесез эшләрдән тыш, тынлыкны бозу белән бәйле төзелеш, ремонт, төяү-бушату һәм башка эшләрне оештыру һәм үткәрү: эш көннәрендә төнге вакытта - 22.00 сәгатьтән 6.00 сәгатькә кадәр, ә ял һәм эшләми торган бәйрәм көннәрендә - 22.00 сәгатьтән 9.00 сәгатькә кадәр.»;

153 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«153. Каты коммуналь калдыкларны җыю, каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарда (мәйданчыкларда) каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешү нигезендә түбәндәге ысуллар белән гамәлгә ашырыла:

а) чүп кабул итү камераларында урнашкан контейнерлар (йорт эчендәге тиешле инженерлык системасы булганда);

б) контейнер мәйданчыкларында урнашкан контейнерлар, бункерлар;

в) региональ оператор тарафыннан бирелгән пакетлар яки башка савытлар.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккач үз көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районының
Адав-Толымбай авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Әхмәтҗанов